# ЭЗЛӘДЕМ, БӘГЫРЕМ, СИНЕ

*СӘЙЯР ХӘБИБУЛЛИН музыкасы*
*ӘХМӘТ ЕРИКӘЙ сүзләре*

Кәккүк кычкыра сирәк кенә,
Сагынуын сөйләп кенә.
Килсәң иде, иркәм, яныма
Көлемсерәп кенә.

*Кушымта:*
Эзләдем, бәгырем, сине,
Еллар буе тилмереп;
Туймас, ахры, мәңге туймас
Күзләрем сине күреп.

Зәңгәр елгалар чылтырап ага.
Нур сибә кояш көлеп;
Алмагачлар ак шәлен ябынган,
Иркәм синең кебек.

*Кушымта .*

Минем юлыма нурлар
Алып кил күбрәк итеп;
Алсу гөлләр өзеп бирермен
Сиңа бүләк итеп.

*Кушымта.*